# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **10.02.2026 ел.**

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Каменка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2025 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Каменка торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында"гы 2025 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2026 елның 10 февралендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Каменка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «2025 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә ризамы” мәсьәләсе, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Каменка торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» 2025 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы карары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Каменка торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Гражданнар җыеннары карарларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Каменка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы карарында «500 сум күләмендә» сүзләрен түбәндәге редакциядә бәян итеп «1000 сум күләмендә»

б) «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Каменка торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» 2025 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы карарында «500 сум күләмендә» сүзләрен түбәндәге редакциядә бәян итеп: «1000 сум күләмендә».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Мәлбагыш авылы, Җәлил ур., 2 йорт («Мәллә» үзәге бинасы); Түбән Якый авылында Кашапов ур., 23 йорт (ФАП), Каменка авылы, Җәлил ур., 1 йорт; Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге Башлыгы А. Й. Әхмәтшин